МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ №214/о БОЕРЫК

«13» 12 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 2008 елның 22 августындагы 681 номерлы карары нигезендә **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Билгеләргә:

социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан, стационар яки вакытлыча торак урыннарын зарури биреп, куркынычсыз районнарга вакытлыча күчерүгә булышлык күрсәтү буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен торак-коммуналь хуҗалыгын реформалау һәм модернизацияләү бүлеге күрсәтә;

социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан торак йортлардагы урыннарны катлаулы авырулардан интегүче аз хәрәкәтләнүче гражданнарга яраклаштыру чараларын уздыру буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен торак-коммуналь хуҗалыгында объектларны эксплуатацияләүгә мониторинг бүлеге күрсәтә.

3. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү секторы мөдире Г.С.Миңнехановага әлеге боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң ун эш көне эчендә аның Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2018
елның «13» 12
№2141боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан, стационар яки вакытлыча торак урыннарын зарури биреп, куркынычсыз районнарга вакытлыча күчерүгә булышлык күрсәтү буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен башкаручы – торак-коммуналь хуҗалыгын (алга таба – ТКХ) реформалау һәм модернизацияләү бүлеге (алга таба – Бүлек).

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан торак йортлардагы урыннарны катлаулы авырулардан интегүче аз хәрәкәтләнүче гражданнарга яраклаштыру чараларын уздыру буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатының ярашлы булуы турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүче – Министрлыкның Эксплуатация һәм ТКХ программаларын гамәлгә ашыру идарәсенең ТКХда объектларны эксплуатацияләүгә мониторинг бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Дзержинский ур., 10 й.

Бүлек урнашкан урын: Казан ш., Кремль урамы, 13, 3 кат, К 108 каб. һәм К

104 каб.

Министрлыкның эш графигы:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр,

җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр,

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Министрлыкның эш көннәрендә.

Җәмәгать транспортында «Кремль» тукталышына кадәр килергә кирәк:

98 номерлы автобус;

«Университет» тукталышына кадәр:

8, 10, 10а, 30, 35, 54, 63, 91, 99а номерлы автобуслар;

7, 17, 20, 21 номерлы троллейбуслар.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Бүлекнең белешмә телефоннары: (843) 231-14-98, (843) 231-14-97, (843) 231-15-26 һәм (843) 231-14-72, (843) 231-14-30, (843) 231-14-91.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.minstroy.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Министрлык урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Министрлык бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.minstroy. tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләренә бәйле мәгълүматлар Бүлек белгечләре тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында һәм Министрлык бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүматлар урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, № 3, 145 ст.) (алга таба – 7-ФЗ номерлы федераль закон);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.) (алга таба – 601 номерлы указ);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләрен раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 45, 6261 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба - 1096 номерлы карар);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциясез оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүчеләр реестры турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 6, 937 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 89 номерлы карар);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының»Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0642 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – Министрлык турында нигезләмә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru, 2018, 31 август) (алга таба - 681 номерлы ТР МК карары).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәдә (алга таба – бәяләмә) күрсәтелгән белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) яки хәбәрләмәдә күрсәтелгән бәяләмәне бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә;

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәләр (алга таба – бәяләмә) бирү. | 681 номерлы ТР МК карарының 2 пункты |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | 681 номерлы ТР МК карарының 2 пункты<br>Министрлык турында нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә | 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүче итеп тану турында карар кабул итү кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 5, 7, 8 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | Бәяләмә бирү турында гариза килгән көннән башлап 30 көн эчендә.<br>Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин, Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан гарызнамәләр җибәрелгән очракта, 30 көннән дә артыгракка түгел.<br>Күрсәтелгән карарны кабул итү срогын озынайту турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү турында оешмадан гариза килгән көннән башлап 30 көн эчендә хәбәр итә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы Россия Федерациясе законнарында каралмаган | Кагыйдәләрнең 6, 9 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | а) дәүләт хезмәте күрсәтү турында билгеләнгән формадагы гариза (алга таба - гариза) (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);<br>б) гамәлгә кую документларының күчермәләре;<br>в) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган, мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртү өчен кирәкле ышанычнамә, документлар мөрәҗәгать итүченең вәкиле аша тапшырылган очракта.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан оешма тарафыннан күрсәтеләүче хезмәтнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерияләргә туры килүен нигезли торган документлар (белешмәләр, сыйфатламалар, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советларның бәяләмәләре һәм башкалар) теркәлергә мөмкин.<br>Әгәр мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерияләргә туры килүен нигезләүче өстәмә документларны тапшыру таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза кәгазен мөрәҗәгать итүче Министрлык бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | Кагыйдәләрнең 5 пункты |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырыла торган айның беренче көненә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең булмавын, оешманың намуссыз тәэминатчылар | Кагыйдәләрнең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавын раслаучы документлар.<br>Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Югарыда саналган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны, шулай ук кабул итүдән яисә дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында «а»-«г» пунктчаларында санап үтелгән очраклардан тыш | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренең кураторы булган урынбасары | 681 номерлы ТР МК карарының 6, 7 пунктлары |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул | Мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында саналган документлар тапшырылмаганда | |

| | | |
|---|---|---|
| итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Бәяләмә бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә (күрсәтү күләменә, срокларына, сыйфатына) карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>б) иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән югары юридик белеме, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмавы;<br>в) бәяләмә бирү елыннан алда килгән ике ел эчендә оешманың аның тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүгә бәйле рәвештәге гамәлләренә (гамәл кылмавына һәм (яки) карарларына карата суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп бүтән дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булуы;<br>г) оешма турында мәгълүматның ачык һәм үтемле булу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый акларында билгеләнгән таләпләргә (булган очракта) туры килмәве;<br>д) бәяләмә бирелгән елдан алдагы ике ел эчендә «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булуы;<br>е) салымнар һәм җыемнар буенча, Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән мәҗбүри түләүләр буенча әҗәтләр булуы;<br>ж) төгәл булмаган белешмәләре булган документларны яки тиешле тәртиптә рәсмиләштерелмәгән документларны тапшыру.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк | Кагыйдәләрнең 7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | 601 номерлы Указ |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү вакыты | Гариза һәм документлар килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү). | 181-ФЗ номерлы федераль закон;<br>880 номерлы ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматлар урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозулар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата дорфа, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгечләре белән бәйләнешкә керү саны: | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен зарури гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Мөрәҗәгать итүче белән эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ), КФҮ читтән торып эшләү урынында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткән очракта алынырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) Министрлыкка 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин | 63-ФЗ номерлы федераль закон;<br>210-ФЗ номерлы федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә проекты әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә бирү;

6) техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта ярдәмендә (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гарызнамә формасы һәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча консультация, кисәтүләр, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында консультация күрсәтү (мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү) турында язу.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче гаризаны Министрлыкның оештыру-беркетмә эше, контроль һәм эш башкару бүлегенә тапшыра.

Гариза почта аша заказлы юллама итеп җибәрелергә мөмкин.

Электрон формада җибәрелә торган гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана (таныклана) һәм электрон чыганаклардан һәм (яки) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып тапшырыла.

Почта аша заказлы юллама рәвешендә тапшырылган яки электрон формалы гариза гомуми тәртиптә карала.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдә шушы Регламентның 2.8 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр барлыгы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән документларны почта аша (электрон почтадан) җибәргәндә, Бүлек белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша (электрон почтадан) җибәрә.

3.3.2. Министрлыкның оештыру-беркетмә эше, контроль һәм эш башкару бүлеге белгече гаризаны һәм документларны Министрлыкның эш башкару күрсәтмәсендә билгеләнгән тәртиптә теркәүгә ала һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Электрон формадагы дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Бүлеккә электрон почта буенча яисә Интернет-кабул итү аша җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Министрлыкка килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.4. Гаризаны карау һәм тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын тикшерү.

3.4.1. Бүлек белгечләре тапшырылган документлар җыелмасын әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килү-килмәвенә карата тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Бүлеккә теркәлгән гариза һәм документлар килгән көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның комплектлы булу-булмавын билгеләү.

3.5. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Бүлек белгечләре дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга), әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә ярашлы рәвештә белешмәләр алу өчен, ведомствоара гарызнамәләр җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.1 пунктындагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга юлланган гарызнамәләр.

3.5.1. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы органнар әлеге Административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны законнарда билгеләнгән срокта бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: гарызнамәләргә җаваплар яисә мәгълүмат булмавы турында хәбәр итү.

3.6. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрнең тикшерелүен гамәлгә ашыра:

кирәкле барлык документлар тапшырылган очракта;

документларның рәсмиләштерелүенең дөреслеген (тапшырылган документларның формасы һәм эчтәлеге буенча законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килүен, документларда кирәкле барлык имзаларның, мөһерләрнең, реквизитларның булуын тикшерә, чистартылган, төзәтелгән урыннарның булмавын тикшерә);

бәяләнә торган хезмәтнең аның эчтәлегенә (күрсәтү күләменә, срокларына, сыйфатына) карата билгеләнгән таләпләргә туры килүен;

иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән югары юридик белеме, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуын;

бәяләмә бирү турында гариза тапшыру елыннан алдагы ике ел эчендә «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булмавын;

салымнар һәм җыемнар буенча, Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән мәҗбүри түләүләр буенча әҗәтләр булмавын;

бәяләмә бирү турында гариза тапшыру елыннан алда килгән ике ел эчендә оешманың аның тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүгә бәйле рәвештәге гамәлләренә (гамәл кылмавына һәм (яки) карарларына карата суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп бүтән дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булмавын;

оешма турында мәгълүматның ачык һәм үтемле булу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый акларында билгеләнгән таләпләргә (булган очракта) туры килүен.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара гарызнамәләргә җаваплар алынган көннән башлап 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүен бәяләү.

3.6.2. Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүен бәяләү нәтиҗәләре буенча Бүлек белгече:

1) теркәлә торган хат һәм 89 номерлы карар белән расланган форма буенча бәяләмә проекты әзерли;

2) әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән очракларда, 3 нче кушымтага туры китерелгән форма буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проектын әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.6.1 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган теркәлү хаты, килештерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проекты.

3.6.3. Теркәлү хаты, министр (министр урынбасары) тарафыннан килештерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.6.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проекты.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.7.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләренең кураторы булган урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә алынганнан соң, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулы белән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләренең кураторы булган урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә алынганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәрләмә.

3.7.2. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне, чират тәртибендә, 15 минут дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

ирекле формада төзелгән техник хата төзәтү турында гариза;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документны;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документларны.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булып торучы документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә) җибәрелә.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны һәм аның белән бергә тапшырылган документларны терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече документларны карый һәм бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү максатларында әлеге Регламентның 3.6.2-3.6.3 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.8.2 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проекты.

3.8.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләренең кураторы булган урынбасары тарафыннан имзаланган үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проекты алынганнан соң, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулы белән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләренең кураторы булган урынбасары тарафыннан имзаланган үзгәртеп

рәсмиләтерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә алынганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документны үзгәртеп рәсмиләштерү турында мөрәҗәгать итүчегә министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган хәбәрләмә.

3.9. Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮ читтән торып эшләү урынында күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат, Эксплуатация һәм ТКХ программаларын гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Көндәлек тикшереп тору Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылышына, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлешенә;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүе.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Министрлык актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) физик һәм юридик затлар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аларның

хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә гаепле затларны җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, шулай ук андагы вазыйфаи затларның һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә вәкаләтле бүлекнең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Идарә җитәкчесе кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Министрлыкка тикшереп торучы министр урынбасары исеменә яисә министр исеменә, министр урынбасары (министр) тарафыннан кабул ителгән карарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, КФҮ, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://minstroy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмә, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6 Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министры
И.Ә.Фәйзуллинга
__________________________(кемнән)
оешманың аталышы, адресы (почта һәм (яки) электрон), телефон номеры (булган очракта)

ГАРИЗА

Сездән социаль юнәлешле коммерциясез оешма

______________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерциясез оешманың исеме)

тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең

______________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәтнең исеме)

сыйфаты аларны күрсәтү өлкәсендә билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирүне сорыйм.

Оешманың чит ил агенты функцияләрен башкаручы коммерциясез оешма булып тормавын һәм бер ел һәм аннан күбрәк чорда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләрен раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карарында расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерияләренә туры килүче атап үтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүе турында раслыйбыз.

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтнең анық эчтәлегенә (күрсәтү күләменә, срокларына, сыйфатына) карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау);

______________________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән югары юридик белеме, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуын раслау)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрне алучыларның аларның күрсәтелү сыйфатыннан канәгать булуын (бәяләмә бирелгән елдан алда килүче 2 ел эчендә оешманың анық тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек, компетенцияләренә ярашлы рәвештә бүтән органнар тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булмавын) раслау)

______________________________________________________________________________

(коммерциясез оешма турында мәгълүматның ачык һәм үтемле булуын раслау)

______________________________________________________________________________

(бәяләмә бирелгән елдан алдагы 2 ел эчендә «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэминатчылар реестрында оешманың булмавын раслау)

Дәлилләүче документлар теркәлә:

1. ______________________________________
2. ______________________________________
3. ______________________________________

______________________________________________________________________________


(Вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.)


«___»____________20__ел.

М.У. (булган очракта)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема




Ведомствоара гарызнамәләргә җавап алу
Теркәлү хатын, бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә проектын әзерләү
Теркәлү хатын, бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрү
Имзаланган документлар
Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе хакында хәбәр итү
Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә документлар бирү

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан уздырылган иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүнең сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча түбәндәге социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан:

______________________________________________

(тулы аталышы һәм төп дәүләт теркәвенә алыну номеры

______________________________________________

социаль юнәлешле коммерцияле оешманың)

күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең:

______________________________________________;

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең исеме)

______________________________________________;

______________________________________________.

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләренә туры килми, түбәндәге нигезләр буенча:

______________________________________________;

(критерияләргә туры килмәүләр күрсәтелә)

______________________________________________.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы

| Вазыйфасы | **Телефоны** | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министрның беренче урынбасары | (843) 231-14-05 | A.AS@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 231-15-23 | I.Nasyrov@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | (843) 231-14-99 | A.Gallyamov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | (843) 231-14-98 | R.R.Hakimov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | (843) 231-14-72 | Marat.Ahmetov@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция-ләү программаларын тормышка ашыру буенча бүлек башлыгы | (843) 264-77-24 | Yuriy.Azin@tatar.ru |